Кукмара муниципаль районы Татарстан Республикасы

Чарлы авыл җирлеге Советы

# КАРАР

28 январь 2022 ел № 1

Чарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 31 январь 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Чарлы авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Чарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 31 январь 2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә, 18.1 статьясын түбәндәге нигездә бәян итеп, (Чарлы авыл җирлеге Советының 2016 елның 19 декабрендәге 30 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 11 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге 2 номерлы, 2019 елның 31 августындагы 11 номерлы, 2021 елнын 9 июнендэге 8 номерлы, 2021 елнын 23 ноябрендэге 26 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәрешләр кертергә:

«18. 1. Җир кишәрлекләренең чик күләме:

«Шәхси торак төзелеше», «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең минималь күләме – 1 000 кв. м.

«Шәхси торак төзелеше» рөхсәт ителгән файдалану төре белән җир кишәрлекләренең максималь күләме– 2500 кв.м, «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен» – 5000 кв.м.»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Җирлек башлыгы Э.Н.Козлов